РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

«15» июнь 2020 ел　　　　Олы Кайбыч ав.　　　　№ 236

Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының
югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел
вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 96 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2014 елның 08 апрелендәге 213 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә: 18 пунктта «рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе　　　　　　　　　　А.И.Рәхмәтуллин